# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ҮРГӘАГАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
# КАРАРЫ

2020 елның 23 сентябре 6№

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, муниципаль хезмәткәрләргә, ТР Әлки муниципаль районының Яңа Үргәагар авыл җирлеге буенча бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәткәрләргә вазыйфаи окладларны арттыру турында

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, Әлки районы Яңа Үргәагар авыл җирлегенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәткәрләргә социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләү шартларын тәртипкә салу максатларында, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында»гы 658 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 5 августындагы «Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешма хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында»гы 655 номерлы карары нигезендә Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, муниципаль хезмәткәрләргә, ТР Әлки муниципаль районының Яңа Үргәагар авыл җирлеге буенча бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәткәрләргә Әлки муниципаль районының Яңа Үргәагар авыл җирлеге Советының 2018 елның 31 маендагы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, муниципаль хезмәткәрләргә, ТР Әлки муниципаль районының Яңа Үргәагар авыл җирлеге буенча бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау турында»гы 7 номерлы карары нигезендә айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Яңа Үргәагар авыл җирлеге Советы рәисе: Ә.Ә.Рәхимҗанов